Бүгенге санда

Редакция мәктәп укучыларының сумкаларын үлчәде. *5 бит*


# Дуслык
Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Җомга 20 ноябрь 2015 ел

№85 (10614)


**21 ноябрьгә һава торышы:** болытлы һава, карлы яңгыр, томан, алмашынучан юнәлешле җил, 6-8 м/с; температура көндез +1°С, төнлә 0°С

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

### МИГРАНТЛАР КОНТРОЛЬДӘ

Кичә, 19 ноябрьдә, район территориясендә законсыз миграциягә каршы көрәш буенча “Легаль булмаган мигрант” оператив профилактик операциясе старт алды. Ноябрь азагына кадәр узачак чара барышында УФМСның Нурлат районы бүлеге полиция хезмәткәрләре белән бергә чит ил гражданнарын тикшерү чаралары уздырачак.

### УКУЧЫЛАР ЙӨЗҮДӘ ЯРЫША

Бүген, 20 ноябрьдә, Г.Хөсәенов исемендәге балалар-үсмерләр спорт мәктәбендә йөзү буенча традицион ДЮСШ беренчелеге уза. Анда җиде яшь категориясендә 50дән артык бала катнаша.

### ФЕРМА ТӨЗҮГӘ – 200 МЕҢ

Бу көннәрдә районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе аша 6 шәхси ярдәмче хуҗалык 2015 елда сөт юнәлешендәге мини-ферма төзүгә киткән чыгымнарының бер өлешен кайтаруга субсидия ала. Бер тапкыр бирелә торган субсидиянең күләме 200 мең сум итеп билгеләнгән һәм ул төзелешкә киткән чыгымнарның 70 процентын тәшкил итә. Субсидия алучылар нигездә Яңа Әмзә, Яңа Иглай, Биляр Озеро авыл җирлекләрендә яши. Республикада ул быел беренче тапкыр бирелә әле.

### ӘНИЛӘРНЕ ГАЗЕТА АША КОТЛАГЫЗ!

29 ноябрьдә билгеләп үтеләчәк Әниләр көне уңаеннан якыннарыгызны газетаның “Әнием, кадерлем...” фоторәсемле проекты аша котларга онытмагыз. Бары бәйрәм уңаеннан гына бездән отышлы тәкъдим! Котлаулар 26 ноябрьгә кадәр генә кабул ителә, ашыгыгыз!

**РАЙОН ГАЗЕТАСЫНА ӘБУНӘ ДӘВАМ ИТӘ.**
*БЕЗ СЕЗНЕ ПОЧТАДА*
*ҺӘМ РЕДАКЦИЯДӘ КӨТӘБЕЗ.*

АНОНС



### САЛЫМНАР АЛДЫНДА БАРЫБЫЗ ДА БЕРТИГЕЗ

*Салымнар түләмәү нәрсәгә китерә? 19 ноябрь көнне суд приставлары һәм дәүләт салым инспекторы катнашында үткән рейд нәтиҗәләре турында язманы киләсе санда укыгыз.*

# Наркотикларга каршы көрәш: ярдәм итик!




Зилия Әксанова фотосы

**Комиссияләр уртак проблеманы уртага салып хәл итә**

**16 ноябрьдән “Үлем белән кайда сатулары турында хәбәр ит” акциясе старт алды.**

Россиякүләм үткәрелә торган бу чарада безнең район сигезенче ел рәттән катнаша. Хокук сакчыларының әлеге акциягә зур игътибар бирүе юкка түгел. Ник дигәндә, чара “ак үлем”гә каршы көрәштә халык ярдәменең ни дәрәҗәдә мөһим булуын күп тапкырлар исбатлады инде.

Чәршәмбе көнне Биляр Озеро мәктәбе базасында беренче тапкыр узган балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау, наркотикларга каршы комиссияләр эшче төркемнәренең уртак күчмә утырышында әлеге тема кызыл җеп булып сузылды. Белгечләр әйтүенчә, районда наркологик ситуация бик яхшылардан түгел. Район үзәк хастаханәсе мәгълүматларыннан күренгәнчә, районда 113 кеше наркотик матдәләр кулланган өчен исәптә тора, шуларның 6сы – 16-17 яшьлек үсмерләр. Аларның барысы да ПДНда исәпкә куелган. Агымдагы елда 3 яшүсмер наркотик куллану һәм аны сату, саклау өчен учетка бастырылган. Шуларның берсе – вуз студенты, икенчесе – шәһәр мәктәбе укучысы, өченчесе беркайда эшләми һәм укымый.

- Елына ике тапкыр мәктәп укучылары арасында наркотик куллануга тикшеренүләр үткәрәбез, - ди район үзәк хастаханәсе наркологы Семен Федотов. – Бәхеткә, быел мәктәп укучылары арасында наркотик матдәләр кулланучылар ачыкланмады. Әмма тынычланырга урын юк. Биляр Озеро кустында да аракы һәм наркотиклар кулланучылар шактый. Районда аноним алкоголиклар һәм наркоманнар җәмгыяте эшли. Атнасына 3 тапкыр очрашабыз. Шунысын әйтәм, бүгенге көндә 17 кеше әлеге җәмгыятькә үз теләкләре белән йөри.

*(Ахыры 2нче биттә)*

АКТУАЛЬ

## Юл һәлакәтен теркәү – ЮХИДИдән башка

**Билгеле булганча, хәзер яңа таләпләр нигезендә, авариягә юлыккан затлар юл-транспорт һәлакәтен полиция хезмәткәрләреннән башка гына терки ала.**

Кызганыч, әлеге мөмкинлектән файдаланучылар саны һаман да аз кала бирә. Ел дәвамында мондый мөмкинлектән файдаланып, районда нибары 2 юл -транспорт һәлакәте генә теркәлгән. ЮХИДИ бүлеге шоферларга ярдәм итү максатыннан махсус ресурс эшләтеп җибәрелгәнлеге турында да хәбәр итә.

- Әгәр авариягә очраган машиналар башка транспорт чараларының хәрәкәте өчен авырлык тудырса, юл-транспорт һәлакәтендә үлүче һәм җәрәхәтләнүчеләр булмаса, йөртүчеләр машиналарын юлдан алырга тиеш, - ди ЮХИДИ бүлеге җитәкчесе Рөстәм Гарипов. - Моның өчен алар юл-транспорт һәлакәтен үзләре теркәргә тиеш.

Яңа закон нигезендә, аварияне теркәмичә, ЮХИДИ вәкилләрен көтеп утыручыларга 1 мең сум күләмендә штраф та салынырга мөмкин, ди. Әлбәттә, әлеге кагыйдәләргә тиз генә күнегү мөмкин түгел. Шуңа күрә Татарстанның дәүләт автоинспекциясе республика йөртүчеләренә ярдәм итү максатыннан махсус мәгълүмати-белешмә ресурс эшләтеп җибәргән. ЮХИДИ идарәсенең рәсми сайтында барлыкка китерелгән gibdd.ru йөртүчеләргә интерактив режимда юл-транспорт һәлакәтен теркәү кагыйдәләрен өйрәтә.

Ресурстан файдалану өчен сайтның “Юл-транспорт һәлакәтен теркәү” бүлегенә - www.gibdd.ru/assistant/dtpra керергә һәм мәгълүмат белән танышканнан соң, андагы сорауларга җавап бирергә кирәк. Бу эш сез юлыккан юл-транспорт һәлакәтенә аваздаш алгоритмга туры китереп башкарылырга тиеш. Юл-транспорт һәлакәтен теркәү ысулларының блок-схема форматында эшләнгән төре дә бар. Ул Интернетка чыгу мөмкинлеге булмаган очракларда уңайлы.

Зилия ӘКСАНОВА

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

ҖӘМГЫЯТЬ

## Наркотикларга каршы көрәш: ярдәм итик!

*(Дәвамы. Башы 1нче биттә)*

Районда агымдагы елда гына да наркотик матдәләр кулланучылар катнашында 14 җинаять теркәлгән. 4 килограммнан артык наркотик матдә әйләнештән алынган.

- 16-27 ноябрь көннәрендә нурлатлыларга, шул исәптән, татарстанлыларга наркотик тарату, саклау һәм куллану белән бәйле мәгълүмат калдыру өчен тагын бер мөмкинлек тудырылды, - ди Россия МВДсы Нурлат районы бүлеге балигъ булмаганнар эшләре бүлеге җитәкчесе Нур Сафиуллин. - Моның өчен түбәндәге телефон номерлары буенча мөрәҗәгать итәргә кирәк: **(8843)291-20-20, 2-11-25, 2-46-42.** Һәр мәгълүмат тәфсилләп тикшереләчәк, алар буенча тиешле карарлар кабул ителәчәк.

Районда наркотикларга каршы көрәшнең бер генә минутка да тынганы юк. Җәй айларында хокук сакчылары, кагыйдә буларак, наркотик матдәле үсемлекләрне юкка чыгаруга аеруча зур игътибар бирә. "Мәк" операциясе җәй башында ук игълан ителә һәм көзгә кадәр дәвам итә. Аның максаты – мәк һәм киндер үстерә торган урыннарны ачыклау, бу эш белән шөгыльләнүче затларны кулга алу. Составында наркотик матдә булган үсемлекләрнең кыргый шартларда күпләп үсә торган урыннарын ачыклап, аларны юкка чыгару шулай ук аеруча мөһим бурычлар рәтендә карала. "Мәк" операциясе барышында районда 0,5 гектарда кыргый шартларда үсә торган, составында наркотик матдә булган үсемлекләр юк ителгән.

Әнә, Бикүле авыл җирлеге территориясендә иске ферма участокларында кыргый шартларда үсә торган, составында наркотик матдә булган үсемлекләргә каршы даими көрәш бара. 1958 елга кадәр бу урында элеккеге "Москва" колхозы киндер мае һәм җиңел сәнәгать товарлары җитештергән булган. Менә шуннан "мирас" булып калган әлеге кыргый үләннәр.

- Кыргый үләннәрне гербицидлар һәм кул көче белән юк итәбез, - ди Бикүле авыл җирлеге башлыгы Рияз Садыйков. – Бу өлкәдә эшне системалы алып барабыз.

Күчмә утырышта социаль куркыныч хәлдәге һәм балигъ булмаган балалар үстерүче гаиләләр хакында да ур-тага салып сөйләшенде. Әлеге зонага кергән Биляр Озеро, Гәйтән, Якушкино авылларында социаль куркыныч 5 гаиләдә 10 бала тәрбияләнә. Әлеге гаиләләрне тармакара социаль патронатка куюның сәбәбе – ата-аналарының исерткеч эчемлекләр куллануы.

- Мондый гаиләләрдә әниләр алкоголь куллана, - ди Биляр Озеро урта мәктәбе директоры Александр Токарев. – Соңгы елларда авылга төрле шәһәрләрдән күченеп кайтучы гаиләләр артты. Алар ана капиталына арзан гына бәягә йорт сатып алалар да, үзләренчә көн күрә башлыйлар. Эчкән кешене эшкә алмыйлар, керемнәре булмагач, баланы бакчага урнаштырып булмый. Ә бит безнең җирлектә, аерым алганда "Сөләйманов Ә.И." хуҗалыгында ел әйләнәсе эш бар үзе. Терлекчелек комплексы эшли, бәрәңге складлары бар.

Балигъ булмаганнар һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе рәисе, район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль – мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары Әлфия Галәветдинова әйтүенчә, ике комиссиянең берләшеп эшләве - яңа форма, һәм аңа зур өмет баглана. Күчмә утырыш эшендә авыл җирлекләре башлыклары, хокук саклау органнары, мәгариф, мәдәният, спорт, хастаханә хезмәткәрләре һәм хокук бозуларны профилактикалау субъектлары катнашуы аңа эшлекле җитди тон бирде.

– Мондый күчмә утырышларны алга таба да проблемалы җирлекләрдә, мәктәпләрдә үткәрәчәкбез. Максатыбыз – гаиләләрне һәм балаларны сәламәт яшәү рәвешенә тарту, - ди Әлфия Салиховна.

Зилия ӘКСАНОВА

МУНИЦИПАЛЬ

## Он-лайн стилендә сатып алулар

**Чәршәмбе көнне муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре муниципаль сатып алулар бүлеге оештырган укуда катнаштылар. 2016 елдан сатып алуларның контракт системасында зур үзгәрешләр көтелә, укуда зур игътибар шуңа бирелде дә.**

Практик дәресне ачып җибәргәндә муниципаль сатып алулар бүлеге начальнигы Җәмилә Мингалиева бүген Нурлатта бу өлкәдә эшнең вакытыннан алда баруын әйтте. Ягъни, бу процессның барлык катнашучылары да алдан курслар үтәләр һәм яңача эшләргә әзерләнәләр. Моның нәтиҗәсе булып республиканың контрольлек итүче органнары үткәргән тикшерүләрнең уңай бәясе тора.


Һәм менә үзгәрешләрнең яңа этабы. Алар сатып алулар планына һәм план-графикларга кагылды. Сатып алулар процессы торган саен күбрәк онлайн-режимга күчә бара, ә анда процессның барлык звенолары да күренеп торачак. Контракт системасы эшенә мониторингны контрольлек итүче органнар хәзер Интернетта да алып бара алалар.

–Бу безгә өстәмә җаваплылык йөкли, - дип эштәге үзгәрешләргә комментарий биреде Җәмилә Минрахмановна.

Мәктәпләр, балалар бакчалары, муниципаль учреждениеләр вәкилләре үзләре үтәргә тиеш булачак таләпләрне карадылар. Хәзер төп игътибар сату-алуларның нигезле булуына, товарның сыйфатына, аның тасвирламасына таләп куюга биреләчәк.

Валентина ВАФИНА

ТӘРБИЯ




9нчы СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ ГАИЛӘ КЫЙММӘТЛӘРЕ ХАКЫНДА СӨЙЛӘШТЕ

## Бүген алар балалар, иртәгә – ата-аналар

**Чәршәмбе көнне китапханәдә Нурлат благочиниесенең яшьләр бүлеге 9нчы сыйныф укучылары белән "Бүген балалар, иртәгә – ата-аналар" дип аталган гаилә тәрбиясе темасына сөйләшү үткәрде.**

Яшүсмерләр өчен гаилә нәрсә ул? Очрашуда катнашкан һәркемнең бу уңайдан үз фикере бар иде, алар бер-берсенә кайсы ягы беләндер охшаш да, аерыла да. Үзләренең гаилә кыйммәтләрен алар тест ярдәмендә билгеләргә тырыштылар. Балаларга төсле кәгазьдән учлар тәкъдим ителде, ә алар анда гаиләдә уңай психологик климат булдыру өчен кирәк булган һәм шулай ук гаилә мөнәсәбәтләрен катлауландыручы характер сыйфатларын яздылар. Соңрак барысы бергә нәтиҗәләре хакында сөйләштеләр. Сөйләшүгә Нурлат районы благочинные иерей Владимир, Серафим Саровский гыйбадәт йорты настоятеле иерей Ростислав һәм күпбалалы әни Ольга Кузьмина да кушылдылар. Ә китапханәчеләр электрон тәкъдир итү күрсәттеләр, анда танылган кешеләр үз гаилә бәхетләренең серләрен ачты.

Маргарита ЛИТТА

БЕР УЧ ХӘБӘР

### НУРЛАТТА УТЛАР ЯКТ
### ЯІ

Быел 224 ут-диодлы яктырт
куелган, 16 исәп узелы – ВЧУ
наштырылган, 11,8 километ
СИП–бишенче линия сузыл
"Жилэнергосервис"ның еллык хез
тен әнә шулай электр белән тәэ
итүнең сыйфатын яхшыртуга кор
ган конкрет саннар аша күрсәте
мөмкин. Нигездә дәүләт прогр
малары аша алып барылган эш
лекнең әйбәт нәтиҗәләре бо
Ут-диодлы яктырткычлар шәһ
нең Чаллы урамына һәм Заречн
Торнаяс, Төрнәс, Сәлән
Тимерлек, Түбән Чаллы, Кие
Илюткино, Гәйтән кебек авыл
га яктылык биргән. Бишенче ли
юклыктан шактый уңайсызлык
чергән авылларның байтагында
хәл төзәтелгән.
–Киләсе елга якынча планнары
ны билгеләдек,–ди предприятие
ректоры Ришат Яруллин.–Ут х
лыгын төзекләндерү эшләрен д
итәргә коллектив та әзер.

Сәкинә НУРУЛ

### ТЕСТЛАШТЫРУДА КАТН

20 ноябрьдән 27сенә кадәр ө
Европа ВИЧ-гепатитка тестлаш
атналыгы узачак.
- Бу акция ВИЧ-инфекциягә т
ренү үтүнең һәр кеше һәм ту
җәмгыятькә нинди социаль-и
сади өстенлекләр бирүен а
максатыннан тагы да зуррак
ачыграк сөйләшү булдыруга к
ган, - ди Нурлат үзәк хастах
баш табибының эпидемис
мәсьәләләр буенча урынба
Татьяна Соренкова. – Халы
релгән мөмкинлектән файдал
ВИЧ-инфекция һәм гепатит
тикшеренү үтәрләр, дип ышан
лабыз. Мәсәлән, бездә ел саен
инфекциягә 13 меңгә кадәр, В
гепатитларга 16 меңнән ар
кеше тикшеренү үтә. Тикшерен
өчен үз участок терапевты
(гомумпрактика табибы) ю
алырга кирәк, ә тикшеренүләр
тә поликлиниканың 115нче к
тында үткәрелә.

Сирень СӘМӘРХ

### "ПОЛИТЗА
### ФИНАЛЫНДА НУ
### ЕГЕТЕ ДӘ

Чәршәмбе көнне К
"Политзавод-2016" проектын
лем бирү сессиясе старт
Сессиядә катнашучылар а
да "Бердәм Россия" па
нең Нурлат җирле бүле
нән "Шикәр заводы" баш
бүлекчәсе секретаре, "Ш
территориаль-иҗтимагый үзи
җитәкчесе Владимир Борзов
Сессиягә проектка гариза бир
кеше арасыннан 100се сөйл
һәм тренинглар ярдәменд
лап алынган. Сессия кысал
лекцияләр, мастер-класслар
рәнү дебатлары, эшлекле у
ул бүген катнашучылар ара
Топ-50не сайлап алу белә
ләнәчәк. Оештыручылар ә
"Политзавод"ка гариза бир
100леккә кермәүчеләр дә и
сыз калмаячак, алар өчен
ел башында белем бирү с
узачак.

Лилия МӨБА

ҺӨНӘР САЙЛАУ

# Ә яшь агрономнар... асфальтка гашыйк




КАРАВЫЛ ТАВЫ УКУЧЫЛАРЫ ҮЗЛӘРЕ ӨЧЕН ОЧРАШУДАН КҮП НӘРСӘ АЛДЫЛАР

**Каравыл Тавы мәктәбенең 9нчы сыйныф укучылары Игорь Савельев белән Сергей Корчуков киләсе елга мәктәпне тәмамлаганнан соң Нурлатның аграр техникумына укырга керергә ниятлиләр.**

Сергей ныклы итеп әретеп ябыштыручы һөнәрен сайлаячакмын дисә дә, Игорь бераз уйлана әле. Әмма һөнәре техника белән бәйле булачагын белә, чөнки күңеле кубрәк машиналар, тракторларга тарта икән.

– Әтием дә техниканы ярата. Минем дә шул һөнәрне аласым килә, - ди егет. Игорь да, Сергей да укуларын тәмамлагач, җирле хуҗалыкка кайтып эшкә урнашуга да каршы түгелләр. Бу һөнәрләргә ихтыяҗ һәрчак бар, эшсез булмаячакбыз, дигән фикердә алар.

Чәршәмбе көнне гимназия базасында үткән авыл хуҗалыгы һөнәрләре сайлау чарасында катнашкан район һәм шәһәр мәктәпләре чыгарылышлары арасында исә Каравыл Тавы егетләре кебек фикер йөртүчеләр тагы да булгандыр, мөгаен. Өстәвенә, район укучылары белән очрашуга Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ришат Хәбипов үзе килгән иде. Республика икътисадында авыл хуҗалыгының тоткан урыны турында кинофильм тәкъдим иткәннән соң ул үсмерләргә мөрәҗәгать итте.

– Аграр юнәлештәге уку йортларында белем алучылар күп булса да, укуларын тәмамлаганнан соң алар авылда төпләнеп калырга, авыл хуҗалыгы тармагында хезмәт куярга ашыкмый, - дип башлады ул сүзен һәм бу тармакта яшь белгечләр өчен кызыксындыру чараларына тукталды. – Югары уку йортын тәмамлап авыл хуҗалыгы тармагына эшкә урнашкан чыгарылышларга бер тапкыр 100 мең, урта һөнәри белем алучыларга 50 мең сум күләмендә түләү каралган. Моннан тыш, яшь белгечләрнең хезмәт хакларына ел дәвамында ай саен 5әр мең сум күләмендә өстәмә түләнә. "Авылның социаль үсеше" дәүләт программасы кысаларында авыл яшьләрен торак белән тәэмин итү, төрледән-төрле субсидияләр бирү мөмкинлеге дә бар.

Быел исә авыл хуҗалыгында элегрәк елларда гамәлдә булган "стипендиат" дигән төшенчә дә кире кайтты. Авыл яшьләре әле укырга кергәнче үк җирле хуҗалык, я булмаса инвестор белән килешү төзи һәм уку дәверендә аңа хуҗалыктан һәм министрлыктан 5әр мең сум күләмендә (ай саен 10 мең) стипендия түләнеп барыла. Ә укуын тәмамлагач, яшьләр һичшиксез шул хуҗалыкка эшкә кайта. Министр урынбасары әйтүенчә, республикада бу мөмкинлектән файдаланып, 100ләп студент белем ала икән инде. Тик алар арасында Нурлат егет-кызлары гына юк: әллә инвесторлар эшләп бетерми, әллә яшьләрне авыл хуҗалыгы тармагы тартмый... Бер караганда, авылда яшәүче гаиләләр өчен бу сумма аз түгел, һәм балаларын укытырга җайлары булмаганнарга менә дигән мөмкинлек бит инде.

Шулай да Нурлат яшьләре авыл хуҗалыгы тармагын сайламый дип әйтү дөрес булмастыр. Әнә, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе мәгълүматларыннан күренгәнчә, бүгенге көндә генә дә аграр университетта 58, ветеринария медицинасы академиясендә 11 кеше укый. Шуларның 15ләбе 5нче курста. Әмма аларның авылга кайтып эшкә урнашасыларына шикләнәләр бирерлек. Чөнки соңгы елларда авылга кайтып эшкә урнашучы яшь белгечләр бармак белән генә санарлык, кайтканнары да тизрәк китү ягын карыйлар икән. Берәү хәтта ярдәм итеп бирелгән 100 меңен дә кире кайтарган ди, әнә. Киресенчә, диплом белән кайткан яшь белгечне тәҗрибәсез дип кире бору очраклары да бар икән. Ә бит хуҗалыкларда белгечләргә ихтыяҗ бар. Бүгенге көндә югары һәм урта махсус белемле 6 агроном, 3 инженер-механик, 7 зооветбелгеч җитешми әнә. Шунда җәйге семинарларның берсендә җиргә хезмәт иткән олы яшьтәге бер агрономның: "Райондагы иң яшь агроном да 50 яшьләрдә инде хәзер. Безнең урынга бер яшь агрономның да килүе күренми. Без китсәк, җирдә кем эшләр?" – дип ачынып сөйләгәне искә төште. Бу сорау хуҗалык җитәкчеләрен, инвесторларны да борчырга тиештер. Юкса, яшь агрономнар асфальтка сыенган арада күбрәк энтузиазм белән эшләп йөрүче агрономнарның соңгылары да пенсия бусагасын атламагайлары...

Лилия МӨБАРӘКШИНА

**МӘГЪЛҮМАТ**

**Очрашуда Казан дәүләт аграр университеты, Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе, Чистай авыл хуҗалыгы һәм Нурлат аграр техникумнары вәкилләре дә катнашып, үз уку йортларының өстенлекләре турында сөйләделәр.**

# Җавапны бергәләп эзлибез

КОРРУПЦИЯГӘ – ЮК!

**Коррупция. Радио, телевидение, газеталар аша без бу әрсез үрмәкүченең бар дөнья һәм илне торган саен күбрәк чолгавы турында белеп торабыз.**

Дөньяда коррупцияне җинаять җаваплылыгы итеп санаган илләр аз түгел. Ул бит хөкүмәткә һәм хакимияткә каршы җинаятьләр категориясенә кергән мошенниклык, караклык, аерата зур күләмдә урлаулар белән бәйле. Коррупциягә теләсә нинди хакимлеккә ия кеше бирелергә мөмкин.

Хокук һәм җәмгыять белемнәре дәресләрендә без замана проблемалары турында еш фикер алышабыз. Безнең тормыш кыйммәтләре, "дөрес яшәү" һәм акчаның гына тормыш мәгънәсе булмавы турында уйланырга мөмкинлегебез бар. Еш кына мондый дәресләрдә укытучыга һәм адвокат, һәм прокурор роленә кереп үз укучыларының күпсанлы сорауларына җавап бирергә туры килә: "Нигә теләсә кайсы "югары" начальник йортына юл салына? Нигә ул яшәгән урамга беренче чиратта газ, су, ут, телефон үткәрелә? Нигә хакимияттәгеләрнең уллары, энеләре өстенлекле хәлдә?" Чиновникларның, хакимият органнарына якын торучыларның башбаштаклыгы гади күзгә дә күренә шул...

Мондый сорауларга җавап бирү җиңел түгел, һәм бирелдә укытучыларга прокуратура, район хакимияте, хокук саклау органнары хезмәткәрләре ярдәмгә килеп, укучыларны республика һәм райондагы хәлләр белән таныштыралар. Безнең гимназиядә берничә ел дәвамында ноябрь аенда хокук белемнәре һәм хокук бозуларны профилактикалау айлыгы кысаларында очрашулар үткәрү традициягә кергә. Бирелдә без – элкәннәр бергәләшеп Татарстан Республикасы җитәкчелегенең гражданнар каршында җаваплылыгын аңлап, Россия Федерациясе субъектлары арасында беренчеләрдән булып республикада коррупцияне булдырмау өчен хәлиткеч чаралар күрүенә инандырырга тырышабыз. Аның нәтиҗәләре бар да инде.

Чираттагы шундый очрашу 16 ноябрьдә үтте. Гимназия укучылары белән очрашуга район прокуроры урынбасары Линар Мисбахов һәм район башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе Федор Терентьев килделәр. Очрашудан укучылар да, укытучылар да күп файдалы мәгълүмат алдылар. "Коррупциягә китергән сәбәпләр нинди? Аны ничек итеп җиңеп була? Нигә без хакимияттә грамоталы, акыллы кешеләр торганда да мондый күренеш каршында көчсезләр?" – балалар шундый сорауларга җаваплар ишеттеләр, презентация белән эшләделәр, Федор Терентьев тәкъдим иткән видеофильмны карадылар.




КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ БЕРГӘ БУЛГАНДА ГЫНА КӨРӘШҮ МӨМКИН

Коррупция сүзен ишеткәндә, балаларда төрле күзаллау туа. Кемдер аны аждаһа кыяфәтендә күз алдына китерә – башын күпме генә киссәң дә яңасы үсеп чыга. Икенчеләрдә ул коррозияне хәтерләтә – күгәрек металлны ашаган кебек, коррупция дә дәүләт аппаратын һәм җәмгыятьнең рухи ныклыгын кимерә. Өченчеләре коррупцияне үрмәкүчкә охшата – ул үзенең корбанын эләктергән кебек, коррупция дә кешеләрне үзенә тарта.

Борынгылар әйткән: "Төге яки бу күренешнең сәбәбен табыгыз, һәм сез нәтиҗәгә ирешерсез". Коррупциягә каршы нинди юнәлештә көрәш алып барырга кирәклеген билгеләү өчен генә булса да аның объектив алшартларын һәм сәбәпләрен белү кирәк. Очрашу күрсәткәнчә, бу бер дә гади эш түгел икән. Әмма барысы да коррупциянең тискәре нәтиҗәләрен кисәткән хәлдә, проблеманы хәл итү мөһимлеген ассызыкладылар. Безгә калса, Россия коррупциянең чәчәк ату чорын үткән инде, аның үсеше һәрчак эре социаль-икътисади үзгәрешләр чорында була бит.

Дәрес ахырына без коррупция белән көрәш аерым кампания белән генә чикләнергә тиеш түгел, дигән нәтиҗәгә килдек. Коррупциягә каршы сәясәт федераль һәм республика хакимиятләренең даими функциясе булырга, ә аның нәтиҗәләре һәрчак халыкка җиткерелергә тиеш. Дмитрий Медведевның: "Гражданнарның хакимиятне контрольдә тотуын аңларга мөмкин: коррупция, системаның наданлыгы барысын да туйдырды, һәм без барыбыз да гаделлек телибез", - дигән сүзләре белән килешми мөмкин түгел. Россиядә коррупцияне җиңәргә мөмкин, моның өчен чын теләк кенә кирәк. Бәхәссез, без моңа ирешәчәкбез! Ирешергә тиешбез!

Дания СИБГАТОВА,

гимназиянең җәмгыять белеме укытучысы

ЖУРНАЛИСТ ЭКСПЕРИМЕНТ ҮТКӘРӘ

# Сумкаңда ни бар, укучы?

**Кем дә булса үз баласының портфелен үлчәп караганы бар микән?**

Ә бит ранец авырлыгы аның хуҗасы авырлыгының 10 процентыннан артмаска тиеш. Сәламәтлек саклау министрлыгы балалар исәнлеге турында кайгыртып, ата-аналарга шундый формула тәкъдим итә.

Без әлеге формуланың ничек үтәлүен гамәлдә тикшерергә булдык һәм шәһәрнең 3нче мәктәбендә зур булмаган эксперимент үткәрергә килештек. Моның өчен медицина хезмәткәре белән берлектә һәр яшь аралыгындагы берәр укучының һәм аның сумкасының авырлыгын үлчәргә булдык. Нәтиҗәдә мондыйрак картина туды.

1нче сыйныф укучысы Илья Ивановның ранецы 2 кг.дан аз гына артык тартты, ә үз авырлыгы 23 кг. булды. Биредә без проблема күрмәдек. Ильяны мәктәпкә әбисе озатса да, сумкасын үзе күтәреп бара икән. Ә менә 4нче сыйныф укучысы Айзилә Минһаҗеваның портфеле ике тапкырга артыграк булып чыкты. 25 кг. авырлыктагы кызчыкка 5 кг.лы сумка күтәреп йөрү җиңел түгелдер!

–Анда нәрсәләр бар?–дип сорыйбыз "рекордсменка"дан.

–Дәреслекләр, дәфтәрләр, көндәлек...

–Шулар гынамы?

–Әйе,–дип уңайсызланыбрак җавап бирде кыз. Сумкамны үзем генә җыям, диюе кебек үк бераз хәйләләве иде бугай...

–Аларның бит мөстәкыйль булып күренәселәре килә,– дип кушылды безнең әңгәмәгә директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары Марина Лукьянова. Ул безнең экспериментта эксперт сыйфатында катнашты. 6,7 сыйныф укучылары Ләйсән Шакирова һәм Данила Ильинның портфельләре 4әр кг.булды. Ләйсән Даниладан 10кг.га җиңелрәк, 30 кг. авырлыкта гына, ә сумкасында спорт формасы да бар икән. Кызның әйтүенчә, алар сумканы әнисе белән бергә җыйлар, ул һәрчак аны контрольдә тота. Иң җиңел букча исә 10 сыйныф укучысы Ксения Абакшинаныкы булып чыкты–бары 2 кг. Сәбәбе гадиул дәреслекләрен мәктәптә калдыра, ә өйдә электрон китаплар буенча шөгыльләнә икән.

–Бу үзенә күрә хәлдән чыгу юлы. Мәктәп мондый очракта укучыларга каршы төшми. Сыйныф шкафларында дәреслекләр һәм башка мәктәп әсбаплары өчен махсус урын бүленә, – ди Марина Лукьянова. – Портфельдә балага уку барышында кирәкле булган нәрсәләр генә булырга тиеш. Әйтик, бу көнгә расписание буенча кирәкле дәреслекләр, дәфтәрләр, канцелярия кирәк-яраклары. Укыту программасы буенча каралган барлык дәреслекләрне, уенчыклар, кызыклы китаплар, шешә белән минераль су алып йөртүнең бала өчен кирәге юк. Ул проблемага гына китерә.

Мәктәпнең шәфкать туташы Тамара Иванова бу фикерне статистика белән раслый:

–Быел үткәрелгән медицина каравы вакытында 137 балада гәүдә торышының бозылуы, 3 укучыда сколиоз, 6сында күкрәк читлегенең деформациясе табылды. Болар–зур саннар. Без участок педиатрлары белән тыгыз элемтәдә эшлибез. Баланың сәламәтлегендә проблема ачыкланса, бу хакта аның ата-анасына хәбәр итәбез һәм ары таба тикшерелү өчен хирургка юллыйбыз.

Шәфкать туташы гәүдә торышындагы проблемаларны парта артында дөрес утырмау белән дә бәйләсә дә, портфель авырлыгын да сызып ташламый.

2003 елда Россия Госсанэпиднадзоры мәктәп дәреслекләренә карата нормалар эшләде. Башлангычлар өчен дәреслекнең авырлыгы иң күбе 300 грамм, 5-6 сыйныфларга – 400 грамм, 7-9 сыйныфлар өчен – ярты килограмм. Өлкән сыйныф укучыларының китаплары да 600 граммнан артмаска тиеш. Боларга бит әле авырлыгы бер килограмм тирәсе булган сумка да өстәлә. Билгеле, ата-аналар да белергә һәм үтәргә тиешләр. Әгәр бала һәр көнне авыр рюкзак ташый икән, бу умыртка баганасының кәкрәюе генә түгел, башка хроник авырулар белән дә яный.

Бу уңайдан без ата-аналарның да фикерләре белән кызыксындык. Аларның күбесе сумкаларны балалар өчен авыр йөк дип санасалар да, аны үлчәп карарга уйламаганнар булып чыкты.

–Балалар өлкәнрәк булган саен, алар дәреслекләрне азрак йөртәләр. 10-11 сыйныфларда кызлар сумкасы күбрәк косметичканы хәтерләтә.Аларның барлык фәннәргә дә бер генә дәфтәре була бугай. Җаваплы балалар да бар, әлбәттә, әмма мин 10 сыйныфта укучыларда минем алтынчыда укучы кызымныкы кебек авыр сумка күргәнем юк, – дип үз фикерләре белән уртаклашты укучыбыз Галина Смирнова. – Спорт формасын һәм алмашка аяк киемен аерым йөртә, кышын исә алар янына чаңгы һәм ботинка да өстәлә әле.

Авыр йөк ташымыйча гына ничек укырга була соң? Үлчәүдән башларга. Анда баланы бастырырга. Сумканы куярга. Алга таба нишләргә кирәклеген ата-аналар үзләре хәл итәр. Ә юлын без күрсәттек инде.

Маргарита ЛИТТА




МӘКТӘП СУМКАСЫНЫҢ АВЫРЛЫГЫ БАЛА АВЫРЛЫГЫНЫҢ 10 ПРОЦЕНТЫННАН АРТМАСКА ТИЕШ

**САН**

СанПин нормалары буенча мәктәп портфеле түбәндәге авырлыкта булырга тиеш:
- 1-2 сыйныф–1,5-2 кг.
- 3-4 сыйныф–2-2,3 кг.
- 5-6 сыйныф–2,3–3кг.
- 7-8 сыйныф–3-3,5 кг.
- 9-11 сыйныф–3,5–4,5 кг.

БЕЗНЕҢ КОНКУРС




## ЕЛМАЮНЫ КОЯШНЫҢ ҮЗЕННӘН АЛАЛАР

Күңелендә игелек, матурлыкка соклану һәм сәнгатьне ярату булганда, һич кенә дә елмаймый яшәп булмый. Балалар сәнгать мәктәбенең "Кояш балалары" хореография коллективында шөгыльләнүче Алия Әһлиуллина белән Алинә Гайнетдинованың да һәр көннәре диярлек яхшы кәеф белән башлана, көндезен яшьтәшләре белән аралашканда да, мәктәптә дә, сәхнәдә дә йөзләреннән елмаю чаткылары китми. Бу көннәрдә исә янә елмаерга сәбәпләре саллы: тиздән үзләрен бию дигән серле дөньяга алып кергән Балалар сәнгать мәктәбенең юбилее көтелә бит. Әлбәттә инде, "Кояш балалары" анда да чыгыш ясаячак һәм кояшның үзе кебек үк тамашачыларга чын ихлас елмаю бүләк итәчәкләр.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

## МӘКТӘП КИТАПХАНӘЧЕЛӘРЕ СӨЙЛӘШТЕ

**12 ноябрьдә Фома урта мәктәбе базасында мәктәп китапханәчеләре район методик берләшмәсенең семинары үтте. Анда " Методик берләшмә – мәктәп китапханәләре квалификациясен күтәрү системасында төп звено" дигән тема каралды.**

Семинарда Фома, Якушкино, Кәкре Атау мәктәпләре эш тәҗрибәләре дә өйрәнелде, берләшмә эшенә йомгак ясалды. Агымдагы ел Әдәбият елы һәм Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган иде, шуңа да күп чаралар әлеге вакыйгалар кысаларында уздырылды.

Быел "Китап – мәгарифнең җаны" дигән темага фәнни-гамәли конференция үтте, "Балалар һәм үсмерләр китабы атналыгын ачу" югары дәрәҗәдә узды, "Нурлат юбилей елында", "Мин Нурлатны яратам, аңа шигырьләремне багышлыйм" брошюралары чыгарылды. "Нурлат һәм Нурлат районы әдәби картасы" челтәр проекты гамәлгә кертелде. Карта белән мәктәп китапханәләре методик берләшмәсе сайтында танышырга мөмкин.

Рузилә МИНГАЛИМОВА, 4нче мәктәп китапханәчесе

САК БУЛЫГЫЗ!

## КОШЛАР ДА КУРКЫНЫЧ ТУДЫРЫРГА МӨМКИН

**Районда яшәүче берәү урманнан алып кайткан матур кошны сыендырып, үзен җитди авыруга дучар итәр, дип уйламагандыр да.**

Ә нәтиҗәдә – ул орнитоз йоктыра. Бу хакта безгә районның баш ветеринария табибы Василий Лысов җиткерде, ул башка нурлатлыларны да кисәтергә теләи:

– Орнитоз – кеше һәм кошлар йогышлы авыруы – ул якыннан аралашмаганда куркыныч түгел. Әмма кеше берни белмичә яки саксызлык күрсәтеп, авыру күгәрчен яки башка кошларны савыктырырга теләи икән, аңа йогышлы авыру куркынычы яный. Орнитоз белән нигездә кошлар авырый. Кошларга вакцинопрофилактика эшләнмәгән һәм кулланылмый да. Орнитоз кешеләргә һава-тамчы яки һава-тузан юлы белән күчә. Кошларда, аеруча кыргый күгәрченнәрдә орнитоз белән авыру куркынычы 30дан алып 80 процентка кадәр булырга мөмкин. Шәһәрдә авыру кошлар күпме соң? Орнитоз буенча мониторинг үткәрелми, статистик мәгълүматлар ветстанциягә авыру кошларны алып килгән кешеләр санынннан чыгып ясала. Йогышлы авыру чыганагын без шулай ачыклыйбыз да. Шуңа да биредә кешенең үзенең саклык чаралары күрүе зур роль уйный.

Валентина ВАФИНА әзерләде

ҖӘҺӘТ ӘҢГӘМӘ

## ҖЫРЧЫ, БАЯНЧЫ, КОМПОЗИТОР...

Нурлатның танылган сәхнә остасы Сабит Миннехановны тамашачылар әнә шулай төрле амплуада уңыш казанган шәхес итеп белә. Тиздән көтелә торган иҗат кичәсендә ул тамашачыларга кайсы ягы белән күбрәк ачылыр икән? Шул сорау белән **Сабит Миннехановның** үзенә мөрәҗәгать иттек.

– Мөгаен, күбрәк композитор амплуасындадыр. Шөкер, бу юнәлештә эшчәнлегем уңышлы бара. Әнә, моннан өч елек иҗатымның 30 еллыгына багышлап үткәрелгән кичәдән соң гына да 15ләп җыр язылган, шуларның дистәдән артыграгы бу кичәмдә да башкарылачак. Яңа җыр – яңа авторлар, тагы да күбрәк сәхнә йолдызлары белән хезмәттәшлек тә ул. Бу юлы да күптәнге иҗаттәш дусларым Раяз Фасихов, Риназ Әхмәтов, Эльмира Сөләйманова, Руслан Кираметдинов, Алмаз Ишморатов, Фирдүс Тямаев, Сиринә Зәйнетдинова, "Сәйдәш" бию төркеме белән бергә С ә й д ә ш һәм Рәшидә Хәсәнҗановлар, Рөстәм Насыйбуллин үзебезнең районнан Рамил Хаҗиморатов, Рәфис, Фәүзия һәм Сирень Кәлимуллиннар, Зөһрә Зарифуллина һәм башкалар чыгачак. Әлбәттә, иҗат кичәмдә гомерлек юлдашым – баянымны да кулыма алмый түзә алмам, җырларга да туры килер әле. Гомумән, иҗат кичәсенә бәйле уй-ниятләр күп, сюрпризлар да булачак, алар Нурлат тамашачысы күңеленә хуш килер, дип, аларны җыр бәйрәменә көтеп калам.

Лилия МӨБАРӘКШИНА сөйләште

6+

Реклама хокукында

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**Кычытканлы авылында** гомер итүче тормыш иптәшем, әниебез, әбиебез, зур әниебез **Гөлсем Гыйрфан кызы Әһлиуллинага** 80 яшь тула. Кадерлебез, сиңа исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, гаилә бәхете телибез, алдагы көнеңдә дә безне шатландырып, исән – сау яшә.

**Ирең Фоат, балаларың Фәнис, Фәния, Зөлфия, Рафаил, Илшат, Рәфис, Булат, Ильвина, Регина, безнең теләкләргә Гайнуллиннар, Гыйльметдиновлар, Байкиннар да кушыла.**



**Яңа Иглайда** яшәүче кадерле әтиебез **Хәмзә Гыйльметдин улы Билдановны** 85 яшьлек гомер бәйрәме белән котлыйбыз. Яшьли ятим калып, бар гомерен туганнарына, балаларына һәм хезмәткә багышлаган әтиебезгә исәнлек – саулык, матур картлык телибез, балаларың һәм оныкларыңның шатлыкларын күреп, имин гомер кичер. Моннан ике ел элек вафат булган әниебез белән 60 ел тату гомер кичереп, безгә үрнәк булдыгыз, барысы өчен дә рәхмәт сезгә.

Син булганда, без бәхетле,
Синең белән якты көнебез.
Безнең белән син дә бәхетле бул,
Сиңа озын – озак гомер телибез.

**Барлык балаларың, кияү-киленнәрең, оныкларың исеменнән Яр Чаллыдан улың Нурис һәм киленең Гүзәлия гаиләсе.**

ФИНАНСОВАЯ КОМПАНИЯ
А-ГРУПП
финансовые решения



Приглашаем на работу
МЕНЕДЖЕРА ПО ПРОДАЖАМ ФИНАНСОВЫХ УСЛУГ

Задачи:
- Руководство подразделением
- Консультирование клиентов по вопросам условий займа
- Заключение договоров с клиентами
- Полное сопровождение сделки

Условия:
- ЗАРПЛАТА от 20 000 рублей (оклад + бонусы)
- Оформление - согласно ТК РФ
- Возможность профессионального и карьерного роста
- Бесплатное обучение

ПРИСОЕДИНЯЙСЯ К НАШЕЙ КОМАНДЕ!
ЗВОНИ: 8-800-100-72-55 (Звонок по России бесплатный)
ПРИСЫЛАЙ РЕЗЮМЕ: agroupp-resume@mail.ru
Реклама

ГРУЗОПЕРЕВОЗКИ «ГАЗЕЛЬ»
В ЛЮБОЕ ВРЕМЯ СУТОК
Т. 8-937-572-99-55.

·ВСЕ ДЛЯ БАНИ
вагонка, двери.
Полы, элементы лестниц. Печи, дымоходы, камни и др.
Т. 8-9274-12-86-71.


Профнастил
Металлочерепица
Сайдинг
Доборки Гладкий лист. Все для Кровли и Забора
г. Димитровград, Мулловское шоссе,39
e-mail: rpn@zavod-p.ru тел: 8-902-128-12-32
e-mail: boss152@mail.ru тел: 8-927-806-89-27
Реклама

КОЕЛАР БОРАУЛАУ.
РАЙОН БУЕНЧА КОЕ БОЖРАЛАРЫН КИТЕРЕП БИРҮ – ТҮЛӘҮСЕЗ.
Т. 8-9274-233-978.

Производитель сельскохозяйственной продукции открывает конкурс на вакансию **ГЛАВНЫЙ ЭКОНОМИСТ**
Опыт работы – ОБЯЗАТЕЛЕН.
Работа в Аксубаевском районе РТ.
Корпоративный транспорт, достойный уровень заработной платы.
**Тел.: 8-927-417-23-27.**



Delko*
ТРАНСПОРТНАЯ КОМПАНИЯ
В СВЯЗИ С РАСШИРЕНИЕМ
ПРИГЛАШАЕМ ПРОФЕССИОНАЛЬНЫХ ВОДИТЕЛЕЙ
НА ПРОФЕССИОНАЛЬНУЮ ТЕХНИКУ



✓Оформление по ТК РФ
✓Иномарки, постоянное обновление
✓Высокий уровень зп
✓Корпоративная связь
✓Страховка
✓Ремонт в СЦ
✓При приеме обязательно наличие у водителя карты для тахографа ЕСТР

ЗВОНИТЕ: +7-962-567-36-23
ТЕЛ. В НАБЕРЕЖНЫХ ЧЕЛНАХ: +7(8552)77-82-82
*Делко. Реклама

12+ **“ТНТ-Нурлат” тәкъдим итә**

**23 НОЯБРЬ**
Музыкаль тапшыру, чуваш телендә.

**25 НОЯБРЬ**
“Нурлат хәбәрләре”,
“Татнефть” хәбәрләре.

**27 НОЯБРЬ**
**“Нурлат хәбәрләре”.**
**“Сиңа дигән җырым”,** музыкаль тапшыру

Программалар **19 сәгатьтә** башлана. **24, 26, 28нче ноябрьдә** иртәнге **7дә** кабатлап күрсәтелә.

## НЕДВИЖИМОСТЬ

*дачный участок, 9 соток, за 4-й школой. Т. 8-927-439-69-54.

*дом. Т.: 2-19-57, 8-917-929-86-81.

*дом, «Афганский» мкр. Т. 8-927-047-40-55.

*2-этажный дом в пос. Единение (35 мельница). Вода, отопление, сан. узел в доме. Хоз. блок: гараж, баня, сарай. Срочно! Т. 8-937-778-12-22.

*2-этажный 5-комнатный жилой дом со всеми удобствами, частично с мебелью. Хоз. постройки: 3 гаража на 5 машин, двор благоустроен, 2 бани, 12 соток. Можно в ипотеку. Ул. Интернационалистов, 9. Срочно! Т. 8-937-778-12-22.

*3-комнатная квартира, с/з, хорошая планировка. Т. 8-927-438-80-24.

*1-комнатная квартира, г. Казань (21 век, Советский район). Т. 8-927-032-22-75.

*дом. Т. 8-927-462-17-01.

*2-комнатная квартира, ул. Нурлатская. 3-комнатная, ул. Кариева. Т. 8-937-774-01-32.

*дом, Мамыково. Т. 8-927-422-24-56.

*3-комнатная квартира, ул. Школьная. Т. 8-937-779-47-44.

*гараж, Гиматдинова, 91. Т. 8-927-403-50-37.

*дом. Т. 8-937-599-75-94.

*3-комнатная квартира, 4 этаж, ул. Кариева. Т. 8-937-616-99-16.

## АВТОТРАНСПОРТ

*«КамАЗ-55111». Т. 8-937-594-02-94.

*Митсубиси лансер, 2008 г/в, в эксплуатации с 2009 г., цвет синий, коробка вариатор, двигатель 1,8. Т. 8-9172-61-52-24.

*«ВАЗ-2110», 2011 г/в. Т. 8-927-481-30-38.

*«Калина-универсал», 2011 г/в, 205000 руб. Т. 8-927-035-87-55.

*«ВАЗ-21099», 1997 г/в. Т. 8-927-037-44-36.

*«Хундай-Туксон», 2008 г/в, пробег 107000 км. Все есть, небитая, полный привод. Т. 8-927-416-80-78.

*«Шевроле-Лачетти», 2010 г/в. Т. 8-927-466-86-79.

*экскаватор «МТЗ-82» с куном. Т. 8-937-592-49-05.

*«ВАЗ-2110», 2001 г/в. Состояние отличное. Торг при осмотре. Т. 8-927-243-06-00.

*«ВАЗ-21010», 2006 г/в, 16 кл. Т. 8-917-391-73-76. Звонить после 16.00 час.

## ДРУГОЕ

*сахар-2250, мука-970, магазин «Юмарт» . Т. 8-927-445-68-55.

*бычки, телята разного возраста. Т. 8-927-483-06-10, 8-917-293-27-47.

*жом. Т. 8-927-400-80-85.

*услуги погрузчика. Т. 8-927-672-31-49.

*ПГС, песок, бут камень, жом. Т. 8-927-672-31-49.

*телята, доставка. Т. 8-927-414-07-18.

*телята, сено, солома. Доставка бесплатно. Т.: 8-929-301-67-76, 8-937-309-03-57.

*поросята. Т. 8-937-770-46-59, 8-84344-4-98-72.

*коза. Т. 8-927-047-40-55.

*поросята, телки стельные, быки, свиньи на мясо. Т. 4-32-77.

*доски осина, сосна, брусья. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.

*корова черно-пестрая. Т. 8-927-045-75-10.

*чугунная ванна, 170, не битая, унитаз, межкомнатные двери 5 шт. Т. 8-927-465-26-60.

*мягкая мебель, б/у. Т. 8-927-415-92-03.

*газовая плита. Т. 8-927-430-55-58.

*сосновый сруб бани 5-ти стенка, размер 6х3,5. Т. 8-917-880-80-48.

*бычки-молодняк. Т. 8-927-870-49-62.

*картофель. Т. 8-927-241-58-83.

*детская коляска в хорошем состоянии. Т. 8-927-421-98-31.

*корова, 3-й отел в феврале. Т. 8-927-490-43-61.

*говядина, телка, молодняк (Халяль). Т. 8-927-245-32-03.

*кровать, диван, стол школьника, муз. центр, дешево. Т. 8-937-599-74-40.

*б/у пластиковое окно, стиральная машинка. Т. 8-927-246-62-09.

*памперсы 2 размер. Т. 8-919-683-52-05.

*литые диски, R 16 от «НИВЫ». Т. 8-927-043-86-04.

*пластиковые окна, 170х120, б/у. Т. 8-937-626-14-51.

*срубы дома (Кировский лес), 8х8 и 8х9. Т. 8-927-247-58-40.

*корова, телята. Т. 8-937-610-57-99.

*дрова. Т. 8-937-003-27-27.

*газовый баллон, бидон дюралевый 40 л., матрац б/у 2 штуки 70х2 м. пружинный, насос, 2-контурный котел «Аристон». Т. 8-927-033-82-30.

*лошадь с жеребенком. Т. 3-72-54.

*новое зимнее пальто, 50 размер, шапка, за полцены. Т. 8-927-248-92-29.

*сено тюками. Т. 8-937-592-49-05.

*телка, отел в феврале. Т. 8-927-480-49-74.

*тушки гусей, индюшат (300 руб/кг), доставка. Т. 8-927-448-04-76.

*ПГС, жом, песок, дрова колотые. Т. 8-937-629-98-97.

**Теплица «НАДЕЖНАЯ» от завода 3х6 – 16 000, гарантия 3 года.**
**Т.: 8-927-040-97-37, 8-917-923-95-82, 8-929-722-29-89.**

## РАЗНОЕ

*ремонт холодильников на дому. Т. 8-927-419-56-48.

*натяжные потолки. Т. 8-9270-365-365, Алексей.

*химчистка мягкой мебели и автомобилей, доступные цены. Т. 8-987-007-17-44.

*доставка жома. Т. 8-987-294-31-04.

*г/п. Т. 8-927-401-11-76.

*ремонт холодильников. Т. 8-927-247-93-50.

*доски - осина, сосна, брусья. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.

*ремонт, настройка компьютеров, Wi-Fi, Интернета. Т. 8-937-005-14-51.

*ежедневно Нурлат-Самара, автовокзал, глазные клиники. Т. 8-927-031-29-33.

*копаем, чистим колодцы. Т. 8-927-481-51-72.

*кузовной ремонт. Т. 8-917-865-30-35.

*ремонт квартир, домов. Электричество, отопление, стена, потолки, пол, перегородки, недорого. Т. 8-937-580-68-04.

*отопление, водопровод, сантехника, установка унитазов, ванн, раковин, обшиваем пластиком. Т. 8-927-411-03-25.

***ремонт компьютеров, установка программ. Т. 8-927-485-70-65.**

*ремонт пластиковых окон. Т. 8-927-249-54-24.

***РЕМОНТ, НАСТРОЙКА: КОМПЬЮТЕРОВ, НОУТБУКОВ, Wi-Fi, ИНТЕРНЕТА. ВЫЕЗД. Т. 8-937-005-14-51.**

## ТРЕБУЮТСЯ

*Вахта в г. Москву. Сборщики(-цы), грузчики, комплектовщики(-цы), упаковщики(-цы), фасовщики(-цы), кассиры. Т. 8-927-272-91-84.

*продавец, на рынке магазин «Обувь». Т. 8-927-406-97-79.

*В ТЦ «Эссен» на постоянную работу уборщики(-цы), график 2/2, полный рабочий день, оформление по ТК. Т.: 8-937-042-24-55, 8-927-601-06-77. («ВолгаРесурс»).

*В ТЦ «Эссен» на постоянную работу дворники, график 2/2, полный рабочий д¬ень, оформление по ТК. Т.: 8-937-042-24-55¬, 8-927-601-06-77. («ВолгаРесурс»).

*репетитор английского языка. Т. 2-54-13.

*повара, кондитеры, бывший «Казбек». Т. 8-927-676-04-85.

*ООО «Сельхозснаб», менеджер и механик-завсклад. Т. 8-927-673-06-03.

## СДАЮТСЯ

*квартира посуточно. Т. 8-927-406-11-06.

*квартира, посуточно. Т.: 8-927-456-05-69, 8-986-712-11-79.

*гараж. Т. 8-927-476-17-63.

*в аренду в парикмахерской рабочие места. Т. 8-937-287-68-88.

*квартира, г. Казань, ул. Чистопольская, м. Козья Слобода. Т. 8-927-241-60-83.

*квартира. Т. 8-917-911-21-28.

*1-комнатная квартира, ул. Нурлатская. Т. 8-927-418-05-17.

*помещение в аренду, мкр. Яшлек, Советская, 193. Т.: 9-22-58, 8-937-288-94-85.

*квартира семейным, без мебели. Т. 8-937-594-03-02.

## СНИМУ

*1-2 комнатную квартиру, с/з и ж/д не предлагать. Т. 8-917-397-00-48.

## Рәхмәт белдерәбез

Тормыш иптәшем, әтиебез, бабабыз **Илгиз Габбас улы САДЫЙКОВНЫ** җирләүдә матди ярдәм күрсәткән туганнарыбызга, сыйныфташларга, тирә – күршеләргә, кабер казучыларга, җеназага килүчеләргә чын йөрәктән рәхмәтебезне белдерәбез.

**Тормыш иптәше, балалары Гүзәл, Фәрит, оныклары.**

## КУПЛЮ

*«ВАЗ», иномарки. Дорого. Т. 8-929-723-31-23.

*АВТО. ДОРОГО. Т. 8-937-588-36-46.

*пух гусиный, мокрый, сухой, старые подушки, перины. Т. 8-987-062-55-26.

*КРС и шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-443-05-43.

*закупаем шкуры КРС по высоким ценам. Т. 8-927-045-44-86.

*кирпичный дом в черте города. Т. 8-927-695-33-66.

*КРС. Т. 8-927-481-30-38.

*КРС, шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-412-29-99.

*шкуры КРС. Т. 8-937-281-75-63.

*радиатор ст. образца на а/м «Газель» ст. образца. Т. 8-927-447-68-90.

*мед липовый 2014 г. и 2015 г. и пчелопродукцию оптом. Приезжаем сами, деньги и тара сразу. Т. 8-927-328-70-37.

*баллоны кислородные. Т. 8-987-292-01-10.

*"Шевроле-Нива". Т. 8-917-261-52-24.

## ПОТЕРИ

*утерянный государственный номер 99-86, считать недействительным.

*утерянный паспорт на имя Шамсегаян Абдулхаковны Галиуллиной серии 9204 №868587, считать недействительным.

*утеряно черное портмоне с паспортом на имя Зинаиды Ивановны Филипповой, нашедшего прошу вернуть за вознаграждение. Т. 8-937-293-32-77.

## СТОЛ НАХОДОК

*найдена связка ключей на дороге напротив школы №3. Обращаться по т. 2-52-16.